# *Коррупциягә каршы нык торыйк*

6 сыйныф укучылары өчен сыйныфтан тыш чара

*Презентацияне әзерләде: сыйныф җитәкчесе, тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы Садриев Равил Мухтарович*

***Бик күпләр коррупцияне авыру белән чагыштыралар.***

***Һәр авыруның килеп чыгуының үз сәбәпләре бар һәм аларны дәваларга кирәк***

***Ә коррупциянең сәбәпләре нидә икән?***

# *Коррупциянең сәбәпләре:*

**-Дәүләт хезмәткәрләренең түбән хезмәт хакы**
**-Законнарны белмәү**
**-Җиңел юл белән керем алу теләге**
**-Вазифаи затларның еш алмашынуы**
**-Илдәге икътисади тотрыксызлык**
**-Коррупциянең гадәткә әверелүе**
**-Халыкның яшәү дәрәҗәсенең түбән булуы**
**-Эшсезлек**
**-Гражданлык җәмгыяте институтларының үсеше түбән дәрәҗәдә булу**

# *Эшчәнлек даирәсенә бәйле юнәлештә коррупция түбәндәге формаларда чагыла:*

- **Дәүләт идарәсендәге коррупция**
- **Парламент коррупциясе**
- **Бизнес буенча коррупция**
- **Предприятиеләрдәге Коррупция**
- **Көнкүреш коррупциясе**

# *Сүзлек эше:*

**шантаж**

**коррупция**

**бюрократия**

**ришвәт, рэкет**

## Дәфтәрләргә язабыз:

- Шантаж – шантажланучыдан, нинди дә булса файда күрү өчен, ул сер итеп сакларга теләгән мәгълүматны кемгәдер җиткерү белән куркыту.

- Коррупция – икътисади даирәдә дәүләт органнарында эшләүчеләрнең җинаятьчел система белән кушылуы, шулай ук сәяси һәм иҗтимагый эшлекләрнең, дәүләт чиновникларының сатылуы.

## Дəфтəрлəргə язабыз:

- Бюрократия – 1)Югары чиновниклар аппараты; 2) административ буталчыклыкка һəм формальлеккə нигезлəнгəн идарə системасы.
- Ришвəт – кемнеңдер үз файдасына законсыз гамəл кылган өчен вазыйфаи затка түлəве яки бүлəк бирүе.
- Рэкет – җинаятьчел элементларның, рэкетирларның законсыз, шантаж һəм куркыту юлы белəн эшмəкəрлəрдəн акча талəп итүе.

# *Түбәндәге ситуацияләрнең кайсысы коррупция очрагына керә?*

**1.Баласын дәвалап терелткән өчен Әминә апа табибка үз бакчасыннан роза чәчәкләре җыеп букет бүләк итте.**

**2.ДАИ инспекторы Нуриев күршесе Садриевка тизлекне арттырган өчен бармак янап калды.**

**3. Депутатлыкка кандидат Сәгъдиев, киләчәктә яхшы заказлар кабул итүдә булышачагы хисабына, коммерция фирмасы белән сайлауларда үзенә акчалата булышу турында килеште.**

**4.Мэр Зариповның эш автомобиле аның хатынын атнага өч тапкыр кибетләргә һәм массаж салонына йөртә.**


**5. Саматов тикшерү өчен белә торып сузып йөрүче тикшерүче Гатауллинга рәхмәт йөзеннән 12000 сумлык телефон бүләк итте.**

**6. Өлкән пешекче мәктәп директоры Хөснетдиновның ашына итне башкаларныкыннан күбрәк сала.**

# Бу рәсемнәр ни сөйли?






1000
1000
Деньги бюджетные! Не красть!

***Бер,ике,өч,дүрт,биш***
***Мин утырта башлыйм.***






**Тәк-тәк...Мин нишләптер оппозиция вәкилләрен күрмим?**




**Россия Федерациясенең Коррупциягә каршы көрәш комиссиясе**

Сезгә үз арагыздагы коррупциягә каршы көрәшергә кирәк

Әйе, әйе, без аның күп ысулларын беләбез.






**Менә бик яхшы! Ә хәзер тагын шуның кадәр – коррупциягә каршы көрәшү өчен.**

# *Халык әйтсә хак әйтә…*

## Түбәндәге әйтем-мәкальләр нинди мәгънәгә ия?

«Майламасаң китмәссең,
теләгеңә җитмәссең» –

ришвәт бирү

«Кул кулны юа,
ике кул битне юа» –

кемнедер сатып алуны
планлаштырган төркем
эшчәнлеге

«Кеше кулы белән
утлы күмер тоту» –

белә торып кемнедер үз
файдаңа закон боздыру

«Казна кәҗәсенең койрыгыннан
тотып торсаң –тун тегәрлек
тиресе булыр» –

дәүләт милкен урлауга карата

## *Коррупцион эшчәнлекнең төп билгеләре.*

- **Катнашучыларның үзара килешүе.**
- **Үзара бурычлы, бәйле булу.**
- **Ике якның да билгеле бер файда һәм өстенлекләр алуы.**
- **Кабул иткән карар хокук боза яки әхлакый нормаларга каршы килә.**
- **Гомуми мәнфәгатьләрне аңлы рәвештә шәхси файда өчен куллану.**
- **Ике як та үзләренең эш-гамәлләрен яшерергә тырышалар.**

**Коррупция белән көрәшне үз-үзеңнән башларга кирәк**
**һәм шуны ук башкалардан да таләп итәргә.**

**Көрәшнең уңышлы булуы хакимият тармакларының үзара килешеп эшләвеннән, аларның җәмгыятьне сәламәтләндерү процессына җаваплы каравыннан тора. Коррупциячел хокук бозуларның барлык чагылышына да тиз арада җавап бирергә һәм гадел җәза билгеләргә кирәк.**